**Мәгърифәтче Бубилар истәлегенә багышланган укучыларның төбакара укулары**

**Секция:** “Туган як тарихын өйрәнүдә авыл һәм мәктәп музейларының роле”

**Тикшерү эше:** “Туган як тарихы – музей сәхифәләрендә”

**Укучының исем – фамилиясе, әтисенең исеме:** Гыйлмуллина Айзилә Мөнир кызы

**Фәнни җитәкче турында мәгълүмат:** Гыйльфанова Рания Рафис кызы

**Эшне тәкъдим итүче оешманың тулы исеме**: ТР Минзәлә муниципаль районы “К.А.Смирнова исемендәге Тат ар Мөшегесе урта гомуми белем бирү мәктәбе”

**Сыйныф:** 7

**Иж- Бубый - 2014**

**Эчтәлек:**


I. **Кереш өлеш**
II. **Төп өлеш**
   - **Туган як тарихын өйрәнүдә музей эшчәнлеге**
   - **Авыл тарихы**
III. **Йомгаклау.**
IV. **Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар.**
V. **Кушымта (фотографияләр - музей экспонатлары, стенд, альбомнар)**

Бабайлар мирасына тугры калыйк!

Борынгыны туплыйк!

Бүгенгене саклап торыйк!

Киләчәк буынга истәлек калдырыйк!

Укучыларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә мәктәп музейлары зур әһәмияткә ия. Музейлар шулай ук туган якның, туган авылның, туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту – тәрбия эшендә зур ярдәм итә.

Безнең мәктәптә дә "Туган якны өйрәнү" музее 1988 нче елдан (Приказ № 195 1988 елдан) эшли. Аңа нигез салучы - тарих укытучысы Әхмәтханова Фәйрүзә апа Әхмәтхан кызы була. Ул 1988-2002 нче елларда музей белән җитәкчелек итә. 2002 нче елдан (Приказ № 4/1 10.09.2002 елдан) хәзерге көнгә кадәр, рус теле һәм әдәбияты укытучысы, Галимарданова Рима апа Нәҗип кызы җитәкчелек итә. Музей мәктәпнең икенче катындагы 32 кв.м мәйданы булган бүлмәсендә урнашкан.

"Туган якны өйрәнү" музееның төп эш юнәлеше - туган якның һәм авылның тарихын, мәдәниятен һәм көнкүрешен өйрәнү.

Музейда эшчәнлек күпкырлы формада алып барыла (экскурсия, лекция, күргәзмә).

Музей эшчәнлегенең юнәлешләре:

- Колхоз тарихы
- Авыл тормышы һәм эшчәнлеге
- Халык иҗаты
- Алҗбомның изге битләре (туган авылыбыз халкы һәм Бөек Ватан сугышы чоры)
- Мәдәният өлкәсе тарихы (мәдәният йорты, китапханә)
- Мәктәпкәчә белем бирү йорты тарихы
- Авылда медицина эшчәнлеге

- Мәктәп тарихы:
  - Педагогик коллектив тарихы;
  - Мәктәп елъязмалары (чыгарылыш сыйныф укучылары)

Мәктәптә музей булдыру өчен 1988 нче елдан экспонатлар туплый башланды. Бу елларда туган як тарихын өйрәнү түгәрәгенә йөрүче укучылар Әхмәтханова Фәйрүзә апа Әхмәтхан кызы җитәкчелегендә авыл халкы арасына чыгып, авыл, мәктәп тарихы турында, авылның күренекле кешеләренә багышланган материаллар, фоторәсемнәр, экспонатлар тупладылар. Бу музейда хәзер 814 экспонат бар. Хәзерге көндә дә туплау эше дәвам итә.

Музейда булучыларны биредә тупланган эш коралларыннан – кул тегермәне, туку орчыклары, жилпуч, җеп эрләгеч, агач көрәк, чабагач, урак, май язгыч, киле, шулай ук тормыш-көнкүреш кирәк-яракларыннан төрле үтүкләр, керосин лампалары, шахтер лампасы, керосинка, төрле йозаклар, сәгатьләр, кайчы, үлчәүләр, бизмән, кистән, әбиләребезнең кул эшләреннән: челтәр, чигелән сөлгеләр, мендәр тышлары, кульяулыклар, сугылган тастымаллар, хатын-кызларның һәм ирләрнең милли киемнәре, чабата, бишек, 18-20 гасыр акчалары, заемнар, гарәпчә язылган иске китаплар, коръән китабы, догалар, дисбеләр, бизәнү әйберләре, төрле значоклар җәлеп итә. Бу экспонатлар укыту-тәрбия процессында киң кулланыла.

Музейда түбәндәге стендлар эшли: ”Мөшегем - гомер бишегем”, ”Колхоз тарихы битләреннән”, ”Батырлар почмагы”, “Апам эзләре буйлап”.

“Якташларыбыз Бөек Ватан сугышында” дигән бүлектә ветераннарыбыз турында мәгълүматлар, тыл ветераннарына багышланган альбомнар, “Батырлар почмагы” дигән стенд, ”Хәтер китабы”, немец солдатының сугыш чорыннан калган каскасы, фляжка, йозак, наган (пистолет), солдатның сугышчан көрәге, поход сумкасы; совет солдатының көрәге, солдат котелогы, патрон, автоматның стволы, граната; Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашларыбызның документлары, орден – медальләре, сугыштан язган

хатлары – әнә шундыйлардан. Бу материаллар укучыларга патриотик тәрбия бирүдә зур таяныч.

Альбомнар:

“Мәктәбем-горурлыгым” бүлегендә мәктәпнең бер гасырлык тарихы, аның директорлары, укыткан укытучылар, чыгарылыш укучылары турында материаллар, альбомнар, ветеран укытучыларның, элекке укучыларының истәлекләре, уку алдынгыларының, медалистларның фотографияләре тупланган. Пионер тарихына караган экспонатлар - галстуклар, значоклар, байраклар, быргылыр, барабаннар, укучы формасы бар.

“Авыл тарихы” бүлегендә ”Колхоз тарихы битләреннән” дигән стенд, колхоз тарихына караган альбомнар, авылыбызның хезмәт алдынгылары турында газета материаллары, күп санда фоторәсемнәр тупланган. Аларны караганда, балалар үз әби-бабаларын танып, алар өчен горурлану хисләре кичерәләр. Тарих дәресләрендә, хезмәт тәрбиясенә, профориентациягә багышланган класс сәгатьләренә бу материаллар үзе бетмәс хәзинә.

Музей материаллары, экспонатлар дәресләрдә, класс сәгатьләрендә, театр атналыклары һәм төрле кичәләр өчен файдаланыла. Авыл халкы да кызыксына, очрашуларга кайткан мәктәпнең элекке укучылары, читтән кайткан кунаклар, очрашуга килгән сугыш ветераннары, өлкәннәр, башка мәктәп укучылары һәм укытучылары музейның даими кунаклары булып торалар. Күпләр гаиләләрендә сакланган, кайдан да булса табылган, үзләре эшләгән яки ясаган әйберләр алып килеп, музейның экспозициясен баеталар. Туган як тарихына битараф булмаган, мәктәпкә һәм туган ягына файда китерергә омтылган бу фидакарь кешеләргә бик зур рәхмәт.

Укытучылар укучылар белән музейда дәрес-экскурсияләр, тәрбия сәгатьләре үткәрәләр, музей материалларын файдаланып, төрле конкурсларда катнашалар, дружина һәм отряд сборлары үткәрәләр.

”Мөшегем – гомер бишегем” дигән тәрбия сәгатенә әзерлек барышында укучылар авыл тарихын өйрәнделәр, истәлекле урыннары һәм аларның килеп чыгышы турында мәгълүмат тупладылар.

**Мөшеге сүзенең килеп чыгышы.**

"Мөшеге" атамасының асылын төрлечә аңлаталар. Башкортстан тарихчысы, фән докторы Р.Г. Кузеев фикеренчә, әлеге атама Бүләр ыруының Мышыгы түбәсеннән килә. Татар галиме, филология фәннәре докторы Ф.Г. Гарипова шундый фикердә. Ә Алабуга дәүләт педагогия институты профессоры Л.Ш.Арсланов, К.П. Корепанов, Е.П.Козаков исә башка фикердә тора. Алар «муш» ягъни «бал корты» зоонимыннан килеп чыгу ихтималы бар дип фаразлыйлар. Әлеге галимнәр М.Г.Атаманов һәм А.И.Туркин фикерләренә таяналар.

Авыл халкында "Мөшеге" сүзенең килеп чыгышы турында мондыйрак фикер бар: «Мөшеге җирләре башта Уфа губернасына кергән. Авыл җирендә башкортлар яшәгән. "мөеш" башкортча «почмак» дигән мәгънә аңлата. (Шулай ук саф лексик диалектизм буларак та «мөеш» - почмак дигән сүз булып тора.) Мөшеге авылы таулар белән әйләндереп алынган һәм өстән караган вакытта почмакны хәтерләтә. Авыл таулар почмагында урнашкан кебек күренә."

«Мөшеге» - көнчыгыш дигәнне аңлата дип тә әйтәләр. Көнчыгышка карап ага торган елгалардан килеп чыккан. (Юныс Юсупов фикеренчә бу шулай).

Авылыбызга багышлап язылган шигырь-җырларны җыйдылар.

Татар Мөшегесе авылы балалар бакчасында эшләгән Гүзәл Мансурова да үзенең хисләрен шигырь юлларына сала:

Горур таулар кочагына алып
Назлый кебек сине Мөшеге
Челтер-челтер чишмәләрнең тәме
Башка сулар гына ишеме?

Матур үтә һәр көнебез синдә,
Туган авылыбыз Мөшеге!
Таулар зәңгәрлеге күңелләрдә
Ярсу яшьлек сөю төсеме?

Күлләрендә йөзгән аккошлар да
Мактый сине моңлы Мөшеге.

Күңел җирси, әллә дөньяның син
Иң гүзәл бер ямьле төшеме?!

Татар Мөшеге авылының иң хөрмәтле кешеләренең берсе, озак еллар буе указлы мулла хезмәтен бөтен халык ихтирамын казаныр дәрәҗәдә башкарган Ханов Вахит бабай авыл турында түбәндәге юлларны язган:

Тат. Мөшеге авылы -
Биек тауның кырында.
Истәлеккә язам әле
Шушы авыл турында.
Биек тауга туры төшкән
Авылның урамнары
Тау өстендә күренеп тора
Ямьле кара урманы.
Шушы урман буйларында-
Безнең иген кырлары,
Ул кырларда эшләп үсә
Егетләре, кызлары
Тау өстендә…тагын тау…

Анысы – Чия таулары,
Көнгә каршы – Салкын чишмә:
Челтерәп ага сулары.
Шушы урман буйларында
Бар Шифалы чишмәләр
Бик ераклардан киләләр,
Сихәт табып китәләр.
Авылыбызны ямьләндерә
Сузылып үскән наратлар,
Килгән кеше хәйран кала
Шул наратларга карап.

Авыл халкы белән дә нәтиҗәле эш алып барыла. Культура елы уңаеннан, сугыш ветераны Н.Галимардановка, тыл ветраннарына концерт кую , ”Ялгызлыкта калдырмабыз” республика акциясенә кушылып, “Буыннар сөйләшүе” этабында ялгыз яшәүче әби-бабайларга ярдәм күрсәтү, шефлык итү.

Шулай итеп, музей елдан-ел байый, яңартылып тора. Укучыларга алдагы буыннарның бай тормыш тәҗрибәсен өйрәтү, авылның тарихы, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру кебек төп максатларга ирешү өчен музей материаллары - чиксез бай хәзинә.

Кулланылган әдәбият  һәм чыганаклар.

1. Вятская  губерния. Список населенных мест со сведениями 1859-1873г. - С. Петербург,1876г.
2. Хасанов М.Х.. Татар энциклопедия сүзлеге. - Казан,1999.

Чыганаклар
1. Авылда һәм авылдан читтә яшәүче өлкән буын кешеләре сөйләмнәре.
2. Музей материаллары.

Кушымта

**“К.А.Смирнова исемендәге Татар Мөшегесе урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе**



**Мәктәпнең “Туган якны өйрәнү” музеена сәяхәт.**



**Музейдагы стендлар:**

***“Мөшегем – гомер бишегем”***




***“Колхоз тарихы битләреннән”***



## *“Батырлар почмагы”*




## *“Апам эзләре буйлап”*



**Музей экспонатлары**

***“Крестьян йорты”***




***“Чигелгән сөлгеләр”***




8. 4.2014 1:25


8. 4.2014 1:25


8. 4.2014 1:26


8. 4.2014 1:26


М-89
8. 4.2014 1:26


8. 4.2014 1:31

*Немец солдатының сугыш чоры әйберләре*




*Совет солдатының сугыш чоры әйберләре*




8. 4.2014 1:27


8. 4.2014 1:27


8. 4.2014 1:27


8. 4.2014 1:27


8. 4. 2014 1:28


8. 4. 2014 1:29



ӘСҺӘР БИЛАЛОВ, РАФАЯЗ КАЮМОВ,
ӘБҮРӘЙ СРУРОВ
8. 4. 2014 1:29


8. 4. 2014 1:31


ИЗОБРАЗИТЕЛЬНОЕ ИСКУССТВО
Н. М. Сокольникова
КРАТКИЙ
ДЕТСТВО ТЕМЫ
КОЛХИДА
8. 4. 2014 1:28


8. 4. 2014 1:32


всех стран,
Победителю
социалистического соревнования
за достойную встречу
50-летия
8. 4. 2014 1:31


КНИГА ПОЧЕТА
М-81
8. 4. 2014 1:32

Музейга сәяхәт



